| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.08.2022 п.г.т.Алексеевское № 337

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының җирле үзидарә органының хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозацияләнгән үсеш нәтиҗәсендә «Белем дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча («Мәгариф» тармагы буенча) укыган гражданнар саны» мәгълүматларын җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлек регламентын раслау турында**

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 21 июлендәге «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары турында» 474 номерлы, 2021 елның 4 февралендәге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 68 номерлы указлары нигезендә

**карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының җирле үзидарә органының хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозацияләнгән үсеш нәтиҗәсендә «Белем дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча («Мәгариф» тармагы буенча) укыган гражданнар саны» мәгълүматларын җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлек регламентын расларга.

2.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәгеТатарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Симашевага йөкләргә.

**Башкарма комитет Җитәкчесе** **О.А. Гайнуллин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
26.08.2022 ел № 337 карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органының хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән үсеш нәтиҗәсендә «Белем дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча («Мәгариф» тармагы буенча) укыган гражданнар саны» мәгълүматларын җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлек Регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Регламентның җайга салу предметы.

Әлеге Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органының хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән үсеш нәтиҗәсендә «Белем дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча («мәгариф» тармагы буенча) укыган гражданнар саны» мәгълүматларын җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлек регламенты Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 21 июлендәге «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 474 номерлы, 2021 елның 4 февралендәге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 68 номерлы указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 542 номерлы карары,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы турында» 920 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 18 апрелендәге «Контроль» модуленең бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасына үзгәрешләр кертү турында» 361 номерлы карары нигезендә эшләнгән һәм җирле үзидарә органының хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән үсеш нәтиҗәсендә «Белем дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча («мәгариф» тармагы буенча) укыган гражданнар саны»

мәгълүматларын жыю һәм мониторинглау тәртибен билгели (алга таба - декомпозацияләнгән күрсәткеч).

Алексеевск муниципаль районында декомпозия күрсәткечләрен жыю һәм мониторинглау буенча жаваплылык үзәге булып «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ (алга таба - мәгариф бүлеге) тора.

1.2. Белешмә мәгълүмат.

Жирле үзидарә органының хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозацияләнгән үсеш нәтиҗәсендә «Белем дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча («мәгариф»тармагы буенча) укыган гражданнар саны» мәгълүматларын жыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлек регламенты максатлары өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары житәкчеләре) һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 542 номерлы карары күрсәткечне исәпләү методикасында билгеләнгән терминнар кулланыла.

## 2. Исәп-хисап стандарты, мәгълүматлар жыю һәм бирү тәртибе

Исәп-хисап стандарты, мәгълүматлар жыю һәм бирү тәртибе декомпозияләнгән күрсәткечне исәпләп чыгару өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча белем алган гражданнар саны («Мәгариф» тармагы буенча).

Мәгълүматлар өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча хезмәтләр күрсәтүче мәгариф оешмасы тарафыннан «Татарстан Республикасында электрон белем» дәүләт мәгълүмат системасына, «Квалификация арттыру» модуленә edu.tatar.ru кертелә.

Мәгариф бүлеге жаваплы хезмәткәре түбәндәге күрсәткечләр буенча хисап чорында белешмәләр жыя:

«Татарстан Республикасында электрон белем» дәүләт мәгълүмат системасына, «Квалификация арттыру» модуленә edu.tatar.ru "Хисаплар" бүлегеннән күчереп алу нигезендә. Муниципаль район (шәһәр округы) буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында рәсми хат белән бирелә.

## 3.Мәгълүматлар бирү составы, вакыты һәм формасы

«Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча белем алган гражданнар саны буенча мәгълүматлар бирү формасы («Мәгариф» тармагы буенча)

| т/б № | Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча хезмәтләр күрсәтүче оешма исеме («Мәгариф» тармагы буенча) | Үлчәү берәмлеге (кеше.) | Мәгълүмат бирү вакыты квартал саен хисаптан соң килүче айның 10 числосына кадәр | Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча белем алган гражданнар саны («Мәгариф» тармагы буенча). |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыфова**